Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Чекалда авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Иске Чекалда торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**13.11.2023ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 13 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта уткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: “2024 елда үзара салым акчаларын кертү өчен Иске Чекалда авыл җирлеге Иске Чекалда торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, I төркем инвалидлардан, студентлардан тыш, көндезге формада белем алучы гражданнардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, ирекле киткән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатыннарын, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юллау белән килешәсезме:

1. Халыкның күпләп ял итү урыннарын ремонтлау һәм алар тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү:

-тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү;

-трактор өчен өстәмә кайтаргыч җиһазлар сатып алу (өем, чапкыч).

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашкан 172 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 88 кеше, бу 52 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 88 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Чекалда авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иске Чекалда торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Чекалда авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Иске Чекалда торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә, I төркем инвалидлардан, тыл

хезмәтчәннәреннән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затларның һәм иректән мәхрүм итү урыннарында булган затлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрдән, мобилизацияләнгән, ирекле катнашучы) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәүче ата-аналардан, ирләреннән йә хатыннардан) тыш.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Устройство, ремонт мест массового отдыха населения и благоустройство прилегающих к ним территорий:

- Халыкның күпләп ял итү урыннарын ремонтлау һәм алар тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү:

-тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү;

-трактор өчен өстәмә кайтаргыч җиһазлар сатып алу (өем, чапкыч).

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
муниципаль берәмлек башлыгы П.М.КОРОЛЕВ